23. Ainutdinov, R. *"Sabantui" – gazeta dlya detei i podrostkov* ["Sabantuy" - a Newspaper for Children and Teenagers]. URL: https://tatarica.org/tat/razdely/sredstva-massovoj-informacii/periodicheskie-izdaniya/sabantuj (accessed: 12.12.2023). (In Tatar)
24. Minnullin, R. (2007). *Sabantuyu starost' ne grozit* [Sabantuy Can't Be Old]. R. Minnullin. V 7 tomakh. T. 7, p. 248. Kazan, Tat. kit. nəshr. (In Russian)
25. Galiev, Sh. (1974). *Tylsymly kozge* [A Magic Mirror]. Yash Leninchy. Mart, 24. (In Tatar)
26. Minnullin, R. (2007). *Balalar donyasyn yangyratyp* [Loudly to the Whole Children's World]. Minnullin R. V 7 tomakh. T. 5, p. 105. Kazan, Tat. kit. nəshr. (In Tatar)
27. Ibragimova, S. (1983).*"Yash Leninchy" hem "Yalkyn" bezde kunakta* [Our Guests - "Yash Leninchy" and "Yalkyn"]. Sovet adabiyaty. No. 9, p.188. (In Tatar)

28. Garifullin, V. (2024). *Yalkynlanyp iҗat itkən idek* [We Created with Passion]. "Tatarica" zhurnaly arkhivy. Kul"yazma. 1 p. (In Tatar)
29. *Tatar yazuchylary "Yash' leninch" gazetasynda ehshləgən chorlaryn iskə aldylar* [Tatar Writers Remember the Times They Worked in the "Yash Leninchi" Newspaper]. 19.04. 2024. URL: https://tatar-inform.tatar/news/tatar-yazucylary-yas-lenincy-gazetasynda-eslagan-corlaryn-iska-aldy-5886467 (accessed: 19.04. 2024). (In Tatar)

# ТАТАР БАЛАЛАР МАТБУГАТЫ ТАРИХЫННАН

**Гөлнара Фәндәс кызы Җамалетдинова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
gulnara.zamaletdinova@kpfu.ru.

**Әлфия Рухулла кызы Мотыйгуллина,**
Идел буе дәүләт физик тәрбия, спорт һәм туризм университеты,
Россия, 420101, Казан ш., Универсиада авылы ур., 35 йорт,
alfiya311065@mail.ru.

Әлеге күзәтү юбилей мәкаләсе характерында, ягъни биредә «Ялкын» журналы һәм «Яшь ленинчы» газетасы чыгуга 100 ел тулу уңаеннан татар балалар матбугаты тарихы буенча материаллар системалаштырылган. Бу басмаларның балаларны тәрбияләүдә, аларның гражданлык карашларын ныгытуда роле тикшерелә. Татар халкына танылган язучыларын, журналистларын, рәссамнарын, композиторларын һәм башка мәдәният эшлеклеләрен үстереп җибәрүгә зур өлеш керткән яшь хәбәрчеләр мәктәбенең нәтиҗәлелеге исбатланды.

**Төп төшенчәләр:** татар балалар матбугаты, «Ялкын», «Сабантуй», «Салават күпере» журналлары, «Яшь ленинчы» газетасы

## Кереш

Татар балалар матбугатының гасырдан артык, төгәлрәге 114 еллык тарихы бар. XX йөз башында белем бирү өлкәсендәге үзгәртеп корулар нәтиҗәсендә тәрбия мәсьәләләре үсү йогынтысында татарларда беренче балалар һәм яшүсмерләр өчен журналлар барлыкка килә. Балалар вакытлы матбугатының башлангычы «Тәрбиятел-этфаль» (1907) журналыннан башлана. Аның нигезен салучы һәм мөхәррире танылган җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче Заһид Шамил (1868–1920) [1, б. 111], [2], [3, б. 7–12], [4]. Журнал эчтәлеге белән энциклопедия характерында була: анда популяр, әдәби, публицистик, хәтта мавыктыргыч материаллар да басыла. Әмма 1907 елның май аенда «Тәрбиятел-этфаль» журналының 5 саны чыкканнан соң, аның нәшер ителүе мәҗбүри туктатыла, басмага әзерләнгән 6-8 саннар дөнья күрми кала [2, б. 188]. Әдәбият галиме Ф. Ибраһимова фикеренчә, аның басылудан туктавының бер сәбәбе итеп, укучылар аудиториясе булмауны күрсәтергә мөмкин, чөнки Мәскәүдә чыга торган журнал татарлар күп яши торган урыннардан ерак урнашкан [5, б. 21].

Татар телендәге балалар басмалары арасында «Ак юл» аерым урын алып тора. Аның нигезен салучы һәм редакторы балалар язучысы, тәрҗемәче, журналист Фәхрелислам Агиев (1887–1938) була. Ул журналның 78 санын чыгарырга өлгерә. Шул кыска гына вакыт аралыгында журнал инкыйлабка кадәр татар һәм рус телле балалар аудиториясен яулап ала, басманы татар балалары арасында иң күп укыла торган журналга әверелдерә [3, б. 2з]. Укучылар арасында зур популярлык яулап өлгергән журнал 1916 елда чыгудан туктый. Ябылуның сәбәбе булып, шул чордагы вакытлы матбугатка хас булганча, финанс кыенлыклары тора.

1917 нче елда Якуб Хәлиуллин балалар өчен «Балалар дөньясы» дигән журнал чыгарып карый. Аның 8 саны гына басылып кала [6], [1, б. 28–29]. Журнал битләрендә әдәби әсәрләр белән беррәттән, фәнни-популяр очерклар, Россия һәм чит ил шәхесләренең биографияләре нәшер ителә. Моннан тыш, тематик журналлар чыгару гамәлгә куела [1, б. 28–29], [6].

Татар балалар басмалары турындагы мәгълүматлар Р. Абызова [7], А. Галиева [8], Ф. Мөслимова [9], Р. Фәтхуллина [10],

Р. Хафизова [11], [12], [13] һ.б. хезмәтләрендә чагылыш тапкан.

### Тикшеренү материаллары һәм методлары

Әлеге мәкаләнең нигезенә бер гасырлык тарихы булган «Ялкын» һәм «Сабантуй» журналларының тарихын өйрәнү максаты салынды. Күзәтү, бәяләү, анализлау вакытында биографик, мәдәни-тарихи ысуллар кулланылды.

### Фикер алышу

Совет дәүләте урнашу нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр балалар басмаларын да читләтеп үтми. Шундый вазифаны 1918 елның 27 сентябрендә Казанда чыга башлаган, шуннан соң 1922 елдан 1931 елга кадәр Мәскәүдә басылып килгән «Эшче» газетасы үти. Өстәвенә 1923 елның 5 августыннан башлап «Балалар почмагы» кушымтасы нәшер ителә башлый. Ләкин ул журнал гына балалар матбугатына булган ихтыяҗны канәгатьләндерә алмый. Бу турыда киң җәмәгатьчелек алдында һәм республика матбугатында М. Җәлил чыгышлар ясый, аны оештырып җибәрергә әзер булуын белдерә. 1924 елда ул «Кечкенә иптәшләр» мәкаләсендә 9–14 яшьлек балалар өчен журнал чыгарырга әзерлек эшләре баруын «Татарстан» (хәзер – «Ватаным Татарстан») газетасында хәбәр итә. Ниһаять, балалар матбугаты турындагы хыял тормышка аша: 1924 елның март аенда Ленин комсомолының татар-башкорт бюросы тарафыннан айга бер тапкыр «Кечкенә иптәшләр» исемле балалар журналы чыгарыла башлый [8, б. 180–181].

Әлеге журналның беренче редакторы Һ. Курмаев була. 1927 елдан башлап, журналны Муса Җәлил җитәкли. «Кечкенә иптәшләр» журналының беренче санында программасы басыла. Анда: «Журналда эшче-крестьян балалары тормышыннан хикәяләр, шигырьләр басылачак. Яшь пионерларның кем икәнлекләре, аларның тормышлары һәм кылган гамәлләре турында язылачак. Кечкенә хәбәрчеләр почмагы булачак», – диелә. 1929 елда журналның исеме «Октябрь баласы»на үзгәртелә. Әмма 1933 елдан журнал басылудан туктый һәм «Пионер каләме» исеме астында нәшер ителә башлый.

Казанда чыга торган «Пионер каләме» журналының җаваплы секретаре итеп балалар язучысы Абдулла Алиш билгеләнә. Әдипнең балалар тарафыннан яратып укыла торган күп кенә әкиятләре шул елларда языла һәм журнал битләрендә басылып чыга. А. Алиш белән беррәттән журнал битләрендә танылган әдипләр Ш. Маннур, М. Әмир, Ф. Бурнаш, Х. Туфан, К. Нәҗми, Ә. Фәйзи, Ә. Бикчәнтәева. Җ. Тәрҗеманов, Ә. Камал һәм башкаларның әдәби әсәрләре дөнья күреп тора. «Пионер каләме» журналында татар әдәбияты әсәрләре белән беррәттән, рус теленнән (А. Пушкин, С. Маршак, Б. Житков һ. б. әдипләрнең) тәрҗемәләр бастырыла, хәтта көнбатыш авторлары Э. Золя турында мәгълүмат урнаштырыла. Журналның тематикасына күпкырлылык хас: союздаш республикалар турында мәгълүматлар, тугандаш халыклар әдәбиятлары үрнәкләре бастырыла, бөек язучылар, композиторлар, сәнгать әһелләренең тәрҗемәи хәлләре белән таныштырып барыла, фән-техника яңалыкларын яктырту күзәтелә, балалар, аеруча пионерлар иҗатын, аларның хатларын бастыру гамәлгә керә. «Пионер каләме», алда чыккан журналлардан аермалы буларак, СССР Югары Советы Президиумы карарларын, партия юлбашчылары турында язмаларны биреп, илдә барган сәясәт белән хәбәрдар булуын дәлилли. Пионерларга үрнәк итеп, В. И. Ленин хакындагы күп кенә язмаларны урнаштыра. Шулай да журнал, Бөек Ватан сугышы елларында бик күп газета-журналлар язмышына дучар булып ябыла.

Әмма сугыш бетүгә журналны кабат торгызу мөмкинлеге тумый. Ул, «Пионер» журналы булып, бары тик 1951 елның ноябрендә генә ачыла. 1953 елга кадәр журналны А. Әхмәт җитәкли, аннары Л. Ихсанова кулына күчә. 1957 елда Л. Ихсанова, «Пионер» дигән басманың бик күп төбәкләрдә (Мәскәүдә, Башкортстанда, Украинада, Белоруссиядә, Эстониядә) нәшер ителүе сәбәпле, аның исемен алыштыру мәсьәләсен күтәрә. Бу вакытта журналның редколлегия әгъзалары Лотфулла Фәттах, Госман Бакир, Гариф Гобәй мөхәррир Л. Ихсанова фикерләренә каршы килмиләр. Бары тик ВЛКСМ өлкә комитетының укучы яшьләр бүлеге мөдире Ләлә Зарипова гына «Пионер» исеменнән читләшүне хуп күрми. Әмма Л. Ихсанова ул вакытта журналны «Ялкын» исеменә үзгәртүгә ныклы фикергә килгән була. Ул үз фикерен дәлилләп, «учак ялкыны, яшьлек ялкыны, пионер ялкыны, хезмәткә дәрт ялкыны», – ди [8, б. 180–182]. Шул рәвешле, 1957 елның июль санынннан башлап, журнал «Ялкын» исеме белән чыга башлый. Әлеге басма журнал битләрендә күп еллар дәвамында «Кечкенә иптәшләр», «Пионер каләме» кебек балалар матбугатында даими

басылып килгән авторлар Хатип Госман, Зәки Нури, Шәрәф Мөдәррисләр белән беррәттән, мәктәп бусагасыннан чыгып баручы илленче еллар яшь шагыйрьләре Равил Фәйзуллин һәм Мөдәррис Әгъләмовның шигырьләре, Ренат Харисның рәсемнәре күренә башлый.

1962 елдан «Ялкын»ның баш мөхәррире булып Роза Хафизова эшли башлый. Оештыру сәләтенә ия булган җитәкче журналның тиражын 80 меңгә җиткерә. Шуның нәтиҗәсендә 1978 елдан башлап журнал офсет ысулы белән төрле төсләрдә нәшер ителә башлый, редколлегия әгъзаларының саны арта. Бу чорда балалар матбугаты өчен үрнәк булган эш стиле барлыкка килә: укучы белән диалог формалаша, һәр хәбәр, мәкалә, хикәя камилләшеп беткәнче эшкәртелә. Әлеге тырышлык эзсез югалмый. Әдәби-нәфис журнал укучыларның иң яраткан басмасына әверелә. Бу вакытта журналны әйдәп баручы редактор белән беррәттән, танылган каләм осталары Габделхәй Сабитов, Хәйдәр Гайнетдинов, Разил Вәлиев, рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов «Ялкын»ның танылып китүе өчен күп көч куялар. Шул елларда Р. Вәлиев сүзләренә язылган «Пионер ялкыны» җыры журналның девизын хәтерләтә. Моннан тыш, шагыйрь Разил Вәлиев рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов белән бергә журналның соңгы битләрендә төсле рәсемнәр белән тасвирланган төрле халыкларның әкият текстларын урнаштыру өстендә күп эшли. Ниһаять, 60 ел дәвамында яшь буынны тәрбияләү өлкәсендә көчле таяныч булып басылып килгән «Ялкын» 1984 елның 5 гыйнварында СССР Югары Советы Президиумы тарафыннан балаларга коммунистик тәрбия бирү өлкәсендәге уңышы өчен Почёт билгесе ордены белән бүләкләнә.

Туксанынчы еллар җиле «Ялкын»ны да читләтеп узмый. Тиражы 50 меңнән дә төшмәгән журнал икътисади каршылыклар алдында югалып кала. Элек киң җәмәгатьчелек, пионер, комсомол оешмалары тарафыннан пропагандаланып торган журналның тиражы кинәт кими. Шушы вакыт аралыгында «Ялкын»ны бер-берсен алмаштырып, Роза Туфитуллова, Җәүдәт Дәрзаман, Эльмира Закирова җитәкли [8, б. 180–182].

«Ялкын» журналының нәшер ителү тарихын тәфсилләп өйрәнгән галим Айсылу Галиева узган гасырның 90 нчы елларындагы басмаларны бүгенге көндә нәшер ителгәннәре белән чагыштырып, болай дип яза: «Бүгенге «Ялкын»ны моннан унбиш-егерме ел элек чыккан журналлар белән чагыштырып та булмый. Ул көннән-көн камилләшә: аның техник мөмкинлекләре дә, бизәлеше дә, кәгазенең сыйфаты да күпкә яхшырак. Соңгы ун-унбиш елда журнал мәктәп укучыларының барлык категорияләре өчен түгел, 12–16 яшьлек яшүсмерләргә атап чыгарыла. Журналны, заманга хас булганча, көнбатыш тәэсире дә читләтеп үтми. Аңа яшүсмерләрне «тинейджерлар» дип атау да, көнбатыш киносы йогынтысы да, шоу-бизнес турында сөйләү дә хас. «Ялкын» яшүсмерләрне бүген борчыган мәсьәләләр хакында яза: ул – этиләр һәм балалар проблемасы да, яшүсмерләрнең социаль-психологик проблемалары да, бала хокукларын саклау темасы да, киләчәк турында уйлану, туган телебез хакында кайгырту да...» [8, б. 182].

Чыннан да, XXI гасырда чыгып килә торган журнал һәрьяклап камилләшә: балаларны кызыксындыра торган «Минем хокукларым», белем алу юлларын күрсәтә торган «Абитура», психологик проблемаларга, үсмерләрне борчыган сорауларга җавап эзләүгә корылган «Оялчан алма», яшьтәшләренә үзләрен күрсәтергә ярдәм итә торган «Кәеф» кушымтасы шундыйлардан. «Балалар хатлары», «Балалар иҗаты», «Борчылам, шуңа язам да», тел һәм әдәбият белгечләре белән бергә әзерләнгән «Җырдай моңлы татар теле», «Әдәбият дәресендә кунак бар», гореф-гадәтләребезне, этнографиябезне чагылдыра торган «Ачык сандык», Казанның меңьеллыгына багышланган «И Казан, серле Казан» рубрикалары заман таләпләренә җавап бирүләре белән аерылып торалар.

«Ялкын» журналы битләрендә танылган язучылар Равил Фәйзуллин, Лена Шагыйрьҗан, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, Луиза Янсуар, Йолдыз Миңнуллина әсәрләре басылу «әдәби-журналист җәмәгатьчелеге өчен иҗади остаханә булуын» дәлилли. Мәктәп елларында басманың балалар редакциясе составында булган Гөлназ Сәфәрова, Айсылу Лерон, Венера Иванова популяр алып баручыга әверелүләре журналның абруен тагын да күтәрә. «Бүгенге «Ялкын»ның «Кечкенә иптәшләр» белән охшашлыгы бик аз кебек: ул чор идеаллары онытылган, җәмгыятьне борчыган проблемалар да башкачарак, укучыларның яшь үзенчәлекләре дә, тормыш рәвеше дә үзгәргән, журналның бизәлеше дә. материалларның бирелүе дә үзгәреш кичергән, эчтәлек тә яңа – әдәби әсәрләрнең тема-

проблематикасы да элекке шикелле күп түгел, публицистик язмалар да жанр ягыннан төрле. Шулай да аларның максатлары бер: ул журнал укучыларын хәзерге буынга лаеклы алмаш итеп тәрбияләү, аларны намуслы, югары әхлаклы кешеләр итеп үстерү» [8, б. 182], [14].

Хәзерге вакытта нәшер ителә торган «Ялкын» журналы балалар өчен чыгып килә торган вакытлы матбугат чарасы гына түгел, ул заманча электрон басма бренд та булып тора. Журналның электрон сайты 7/24 форматы буенча эшли, анда басыла торган мәкаләләр бүгенге көн балалары ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә. Социаль челтәрләр белән эшләүдә брендның яшь буын арасында танылуын арттыруга, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерүгә, актив гражданлык позициясен ныгытуга, милләтпәрвәрлек хисләре тәрбияләүгә, шулай ук үсеп килүче буында милли үзаң формалаштыруга басым ясала.

Җөмһүриятебездә балалар өчен басылып килгән «Ялкын» белән беррәттән, балалар өчен «Яшь ленинчы» газетасының да чыга башлавына быел 100 ел тула. Бер гасырлык тарихы булган басма 1924 елның 10 октябрендә чыга башлый [1, б. 97]. Дөрес, соңыннан ул «Сабантуй» журналы итеп үзгәртелә.

1923 елда комсомол җитәкчесе Шәһит Шаммазов Казандагы Габдулла Тукай исемендәге балалар йортында татар балаларының беренче пионер отрядын оештырганнан соң, аның «Яшь пионер» дигән кулъязма газетасын да бастыра башлый. 1924 елның 10 октябреннән башлап газетаның исеме «Яшь ленинчы» дип үзгәртелеп, 1500 данә тираж белән чыга башлый. Газетаның баш мәкаләсендә максатлары һәм бурычлары түбәндәгечә билгеләнә: «Яшь ленинчы» барлык пионерларга һәм эшче-крестьян балаларына ничек яхшырак эшләргә, ничек берләшергә, ничек пионер сафларына басарга икәнлеген күрсәтәчәк». Газетаның беренче редакторы Шәһит Шаммазов булса, беренче тәҗрибәле хәбәрчеләре Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим, Әмирхан Еники, Хатыйп Госман, ә яшь хәбәрчеләре исә Мөхәммәт Садри, Зәки Нури, Шәрәф Мөдәррис, Гали Хуҗиев, Мәхмүт Хөсәен, Мифтах Вәдүт, Мансур Гаяз була. Соңыннан алар күренекле язучылар булып китәләр [1, б. 97].

Шул хәлендә «Яшь ленинчы» газетасы 1936 елга кадәр даими басылып килә. Басманың бу чоры күп кенә танылган шәхесләрнең истәлекләрендә яктыртыла. Мәсәлән, Хатыйп Госман 1974 елда язылган хатирәләрендә газетаның Урал өлкәсенең Сулмаш авылында барлык кешеләр тарафыннан көтеп алынган, яңалыкларга бай газета булуын ассызыклый. Газета Мәскәүдән, Свердловскидан, Казаннан алдырыла. Пионер отряды төзегән малайлар газета килү белән, кичләрен кешеләр җыела торган җирләргә барып, газета битендәге язмаларны кычкырып укыйлар. Ә язу-сызудан ерак торган агайлар аларны сихерләнеп тыңлыйлар. Балалар үзләре газетаны хөрмәтләп саклаганнар, һәр номерын кабат-кабат укыганнар, шигырьләрен ятлаганнар. Алар пионерларның формасы булуын да беренче тапкыр газета битләрендәге рәсемнәрдә, фотосурәтләрдә күреп беләләр. Шуннан соң, заман модасыннан калышмас өчен чалбар балакларын сызганып куя торган булалар [15].

Танылган шагыйрь Нури Арсланов истәлекләрендә «Яшь ленинчы» газетасын 1925 елдан бирле белүе әйтелә. Башта ерак Казахстан җирендә Күкчәтау шәһәренең татар җидееллык мәктәбендә укыганда, газетаны почтадан көтеп алуын, яратып укуын искә төшерә. 1928 елда Казан сәнгать техникумына укырга килгәч тә, шагыйрь газетаны даими укый, үзе дә әз-мәз генә язышa башлый. Ә язучы Ибраһим Салахов газетада әдәби бүлек мөдире, аннан редактор ярдәмчесе булып эшли башлагач, ул Нури Арслановны редакция эшенә рәссам буларак тарта [16].

Шагыйрь Гадел Кутуй исә, «Яшь ленинчы»да шигырьләр бастырмаган, ул балаларның белемен күтәрү, дөньяга карашын киңәйтү өчен махсус «Китапларны ничек укырга?», «Әдәбият түгәрәкләре оештырыгыз», «Нәрсә ул матур әдәбият?», «Түгәрәктә нәрсә эшләргә?» кебек рубрикалар алып барган. Моннан тыш, ул балалар белән хат алышкан. Шунда ук газета укучыларын дөнья әдәбиятының күренекле вәкилләре һәм аларның әдәби җәүһәрләре белән таныштыру өлкәсендә көч куйган [17].

Мәгълүматларга караганда, газета белән Һади Такташ та тыгыз элемтәдә торган. Чөнки газета битләрендә бик еш булмаса да, аның шигырьләренә охшаган шаян шигырьләр очрый («Актив – Пассив», «Тәүфыйклы песи», 1928). Әмма алар төрле тәхәллүсләр астында басылган: Һ. Шатун, Бәдрүш Мокамай [18].

Шагыйрь Фатих Кәрим газета белән язмышын мәктәптә укыган чорда ук бәйли. Ул 19 яшендә редакция әгъзасына әйләнә. Өстәвенә ул бер ел дәвамында (1930 елда)

газетаның җаваплы сәркатибе булып эшли, хикәяләрен бастырып чыгара [19].

Балалар язучысы Абдулла Алиш зур язучы булу белән бергә газетаның актив хәбәрчесенә әйләнә. «Яшь ленинчы» газетасында аның 30 дан артык хикәясе, әкиятләре, пьесалары басыла. Ул газетага язышып торучыларга киңәшләр дә биреп, өйрәтеп тә торган. Үзәк пионерлар клубында әдәбият түгәрәген җитәкләгән. Әлеге түгәрәк әгъзалары Г. Хәсәнов белән Г. Галиуллин ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты оештырган балалар әдәби әсәрләре конкурсында җиңү яулаулары да газетада хәбәр ителә [20].

«Яшь ленинчы» газетасында җаваплы сәркатип булып эшләгән Саимә Ибраһимова газетаның 60 еллыгына багышлап, «Совет әдәбияты» журналында бастырган мәкаләсендә газета сәхифәләрен балалар язмышы белән бәйләп: «Егерменче елларда пионерлар ярдәме белән мин ятим калган балаларның күңелләрен җылыттым, укый белмәгән кешеләрне укырга өйрәттем, кулаклар белән көрәштем, колхозлар төзештем. Мәктәптә, колхоз кырларында, походларда һәм пионер сборларында мин һәрвакыт ал галстуклы балалар белән бергә булдым. Учак янында без җырлар җырладык, җиңүләребез өчен шатландык...», – дип яза. Шушы ук мәкаләдә газетаның басылудан туктап торган вакытында да элекке хатирәләре балалар күңелендә саклануын, аларның авыр физик хезмәтендә күңелләрен җылытып торган маяк булуын искәртеп уза. 1961 елдан газетаның кабат нәшер ителүенә шатлана [21].

Халыкның рухи тәрбиячесе булган әдипләр һәм галимнәр (Н. Исәнбәт, С. Хәким, Ф. Хөсни, М. Әмир, Г. Минский, Г. Галиев, Н. Арсланов, И. Туктар, Г. Бакир, М. Садри, Л. Ихсанова, Җ. Тәрҗеманов, З. Туфайлова, профессор В. Хаков) җәмгыятьнең киләчәге балалар икәнлеген аңлап, «Яшь ленинчы» газетасы белән тыгыз элемтәдә торганнар. Басма битләрендә әдәби әсәрләре белән беррәттән истәлекләрен, язучы остаханәсе серләре белән дә уртаклашканнар.

Татар балалар әдәбияты әсәрләре иң элек «Яшь ленинчы» газетасы битләрендә бастырылган. М. Мәһдиев, Г. Әпсәләмов, Н. Фәттах, Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин, М. Шабаев, А. Әхмәт, Ш. Маннур, Ш. Галиев, Х. Туфан, Н. Юзеев, Г. Бәширов, Р, Төхфәтуллин, Ә. Баянов, Ә. Еники, Ш. Рәкыйпов, Р. Харис, А. Гыйләҗев, А. Шамов, К. Миңлебаев, З. Нури, композиторлар Н. Җиһанов, М. Яруллин, Р. Яхин, З. Хәбибуллин, рәссамнар Л. Фәттахов, Х. Якупов газета редакциясе белән тыгыз элемтәдә торганнар, аның авторы да, хәбәрчесе дә булганнар.

Газетаның хәбәрчеләре язучылар, шагыйрьләр, галимнәр генә булмаган, аны чыгаруда мәктәп укучылары да актив катнашканнар. Күренекле рәссам Х. Якуповның беренче иҗат җимешләре газета битләрендә басыла. Үзенә газета ясаган йогынтыны искә төшереп, ул болай дип яза: «Безнең класс малайларыннан Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган сәләтле шагыйрь Мөхәммәт Әхмәтгалиев, хәзерге атаклы рәссам Лотфулла Фәттахов, татар балалар язучысы Җәвад Тәрҗеманов, тарих фәннәре докторы, Патрис Лумумба исемендәге Халыклар дуслыгы университеты профессоры Габделхак Галиуллинның һәм башкаларның беренче әсәрләре «Яшь ленинчы» битләрендә басылды. Без ул чакта Казандагы 18 нче татар мәктәбендә укый идек» [22].

«Яшь ленинчы» газетасы тарихы ил язмышыннан аерылгысыз. 1924 елда чыга башлаган газета 1936 елга кадәр ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм пионер оешмаларының Республика советы органы буларак, даими рәвештә басылып килә. Шул елдан башлап, «Яшь ленинчы» белән «Кызыл Татарстан» газеталарының редакцияләре берләштерелә. Шуңа күрә балалар өчен мавыктыргыч газета булган «Яшь ленинчы» 1936–1941 елларда «Кызыл Татарстан» газетасының «Пионер бите» сәхифәсе рәвешендә генә басыла. Аның өчен материалларны «Яшь ленинчы»ның элеккеге журналистлары М. Дибаева, М. Нуретдинова әзерләп бирә [23].

Газетаның төрле еллардагы мөхәррирләре булып – Ш. Шаммазов (1924–1929), Һ. Измайлова (1929–1931), Л.Г. Гыйльми (1931–1937), Г. Хәбибуллин (1937–1941), В. Ф. Ихсанова (1960–1977), Р. Р. Туфитуллова (1977–1986), Р. М. Миңнуллин (1986–1995), Л. Н. Гыймадиева (1995–2004), А. М. Гыймадиев (2004–2017), И. Ф. Фазуллин (2017–2020), З. З. Хөснетдинова (2020 елдан башлап) эшлиләр [23].

1961 елдан соң газета үзенең элекке традицияләрен кире кайтарырга омтыла. Газетадагы рәсемнәрен, әдәби әсәрләрен җибәреп торган мәктәп укучылары соңыннан танылып китәләр: атказанган рәссам Әсгать Сәфәргалин, шагыйрьләр Шәрәф Мөдәррис, Ркаил Зәйдулла шундыйлардан. Газета редакциясе бик күп

язучыларга зур юлга чыгу өчен башлангыч булган: шигырьләрен бастырган Равил Фәйзуллин үзе дә озак еллар «Казан утлары» журналын җитәкли, Нургали Булатов «Ватаным Татарстан» газетасының җаваплы сәркатибе була, Мәҗит Вәлиуллин «Мәгариф» журналының баш мөхәррир урынбасары вазифасын үти, Ленарис Леронович Гыйльфанов (Ләбиб Лерон) «Безнең мирас» журналын баш мөхәррир буларак җитәкли [24, б. 248].

Газета танылган балалар шагыйре Шәүкәт Галиевка да йогынты ясый. Ул газетаны «балалар күңелен яктырткан тылсымлы көзге», дип бәяли. «Яшь ленинчы»га үз рәхмәтләрен белдереп, бу вакытлы басма «балаларның үз ишләре булган образ» тудырырга ирек бирде дип, Шәвәли образын тудыруга ярдәм итүен әйтә [25].

«Яшь ленинчы» газетасы балалар язучысы Роберт Миңнуллинның ярты гасырга якын язмышы белән бәйле. Ул университетны тәмамлаганнан соң, 1973–1977 елларда «Яшь ленинчы» газетасында хәбәрче булып эшли. Лирик шигырьләрен, балалар өчен дә беренче шигырьләрен шул чорда яза һәм бастыра.

Шагыйрьнең «Яшь ленинчы» газетасы белән бәйле истәлекләре «Сабантуй сабаклары» мәкаләсендә бирелә. Бирелә ул кече яшьтән газетага булган мөнәсәбәте белән уртаклашып, тормыш юлында газетаның ролен болай билгели: «Казанга килеп укый башлагач кына, «Яшь ленинчы»ның нинди җитди, бик тә билгеле гәзит икәнен белдем. Балалар гына түгел, яшьләр дә, олылар да яратып укый торган балалар матбугаты булып чыкты ул. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары арасында ул аеруча популяр иде. Ә инде аның битләрендә шигырьләр бастырып чыгару әдәби мохиттә иң зур мәртәбәләрнең берсе... Анда басылып чыккан һәрбер шигырь, һәрбер хикәя үзе бер олы вакыйгага әйләнә» [26, б. 105].

Шагыйрь газетада басылырга теләп, шигырьләр яза башлый. Аның газетада беренче басылган шигырьләре «Мин бабама охшаган» һәм «Әнвәрнең хыялы» була. Ә газетага эшкә ул Рәдиф Гаташ тәкъдиме белән килә. Гәзит-журнал редакцияләренең барысы да ул вакытта Бауман урамындагы легендар Матбугат йортында иде. «Матбугат йортының озын коридорлары буйлап бер генә тапкыр узсаң да, татарның әллә никадәр аксакалларын, күренекле шәхесләрен, яшь каләмдәшләреңне очратасың. Татар дөньясының кендеге нәкъ менә шушы Матбугат йорты иде ул чакларда», – дип нәтиҗә ясый яшь журналист [25, б. 105].

Ярты елдан ул әдәбият һәм сәнгать бүлегендә, балалар шагыйре Хәкимҗан Халиков янында эшли башлый. Бу елларда Роберт Миңнуллин балалар иҗаты белән мавыгып китә. Ул редакциягә килгән шигырьләрне, әкиятләрне, рәсемнәрне, хәбәрләрне, төрле-төрле сораулар куелган хатларны билгеле бер системага сала, газета битендә бастырыла торганнарын эшкәртә, төзәтә, кайберләре яңабаштан язып, көн саен «Яшь ленинчы» номерларына материаллар әзерли. «Иң авыры – балаларга җавап язу эше», – дип искә ала журналист. «Ничек кенә үкенечле булмасын, балалардан килгән язмаларның күбесе гәзиттә бастырырлык булмый торган иде». Укучылардан килгән хатлар берсе дә җавапсыз калмый. Аларда Роберт Миңнуллин баланың күңелен төшермәскә тырышкан һәм ни өчен басып булмавын аңлатып биргән. Шул хатларны язу барышында ул журналист һәм әдип буларак, үзе дә тәҗрибә туплаган.

Шул рәвешле, Роберт Миңнуллин әдәбият һәм сәнгать бүлегендә эшләү дәвамында зур әдәби мәктәп үтә. Беренчедән, кабатланмас шәхесләр Нәкый Исәнбәт, Мирсәй Әмир, Шәйхи Маннур, Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Габдрахман Әпсәләмов, Нәби Дәүли, Габдрахман Минский белән таныша. Икенчедән, классиклар үзләренең яңа роман-повестьларыннан өзекләр бастыруны зур мәртәбәгә саныйлар. Өченчедән, Мөхәммәт Мәһдиев, Мәҗит Рәфыйков, Рафаил Төхфәтуллин, Әдип Маликов, Габдулла Шәрәфи кебек урта буын әдипләре дә, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким кебек аксакалларыбызның шигырь бәйләмнәре газета битләрен һәрчак бизәп тора. Газета укучылар һәрвакыт Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Мингалим, Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗанов кебек горур табигатьле шагыйрьләр әсәрләрен көтеп алалар.

Шулай тәҗрибә туплый барган Роберт Миңнуллин күзәтүләр ясарга өйрәнә. Аксакаллар белән уртак тел табып, «Синә әйтер сүзем бар», «Без бәләкәй чакларда» дигән рубрикалары аша укучылар күңелен яулый. Шуңа өстәп, газета нәшрияты әдәбият-сәнгать әһелләре өчен остаханәгә әверелә: Н. Фәттах белән Х. Сарьян җитәкчелегендә яшь хикәячеләр клубы оеша; Х. Сарьян «Әдәби осталык мәктәбе»н алып бара; Ф. Шәфигуллин очерклар бастыра; Г. Бәширов «Туган ягым – яшел бишек» рубрикасын җитәкли [26, б. 105].

Газета хезмәткәрләре балалар язучыларының иҗатларын пропагандалау өчен яңа форма эзләп табалар. Балалар арасында әдипләр иҗатын пропагандалау максатыннан классикларның (Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, А. Алиш, Н. Исәнбәт) иҗатларына багышлап, махсус саннар чыгара башлыйлар. Материалларга балалар теле белән язылу, бала күңеленә үтеп керерлек булу шарты куела. Аларны әзерләү барышында язучының иҗат лабораториясе өйрәнелә, әдипнең гаиләсе, туганнары белән элемтәгә кереп, кызыклы дәлилләр туплана, әдәбият галимнәреннән, белгечләрдән киңәш-консультацияләр алына.

Оештыру сәләтенә ия булган, редакциядә эшләп тәҗрибә туплаган Р. Миңнуллинга Язучылар секциясенең секретаре булырга тәкъдим итәләр. Ул секциянең эш планнарын төзи, секция утырышларын әзерли, уздыра, беркетмәләрне тәртипкә китерә. Даими рәвештә редакция белән уртак утырышлар уздыра. Ә 1986–1994 елларда Р. Миңнуллин газетаның баш редакторы була.

1961 нче елдан башлап «Яшь ленинчы» газетасы балалар белән элемтәне ныгыту өчен ел саен төрле акцияләр уздырып тора. Шуларның кайберләре:

| | |
|---|---|
| 1961 | «Дуслык» нефть магистрале;<br>Казан – Уфа дуслыгы;<br>Пионерлар – Ватанга. |
| 1964 | Бер телем ипи турында;<br>«Яшь ленинчы» призына спорт көрәше. |
| 1965 | «Нинди иркен минем туган җирем» дигән темага шигырь, рәсем, фото конкурсы;<br>«Татарстан пионеры» өчен тимер-томыр җыю;<br>Әдәплелек мәктәбе;<br>Тапкырстан иле;<br>«Лачын» операциясе. |
| 1966 | Татарстан чикләрендә дуслык учаклары;<br>Һәр мәктәптә – спорт мәйданчыгы булсын! |
| 1967 | «Бертуган галстуклар»;<br>Стена газетасы конкурсы;<br>«Бәхәс» клубы. |
| 1968 | «Ант» операциясе;<br>Һәркайда агач, чәчәк утыртыйк! |
| 1971 | «Яшь ленинчы» автоколоннасына металл җыю;<br>Ульяновлар Татарстан җирендә;<br>«Яфрак» операциясе;<br>«Яшь химиклар» мәктәбе. |
| 1973 | Тимур иле;<br>ГДРга читтән торып сәяхәт. |
| 1974 | «Туган ягым – яшел бишек» операциясе;<br>Яшь батырларга багышланган 10 көн. |

Газета балаларга дуслык, үзара ярдәм, гаделлек, Ватанга мәхәббәт идеалларын сеңдерә, тәрбияли. Бу концепция газетаның яшь аудиториягә адресланган башка массакүләм мәгълүмат чаралары компонентлары (журналлар, теле- һәм радиожурналистика) һәм педагогик процесста катнашучы төрле социаль институтлар (мәгариф, фән, Мәдәният, классик һәм заманча балалар әдәбияты) белән актив хезмәттәшлек итү идеясенә нигезләнгән. Бу балалар һәм яшүсмерләрне иҗтимагый процессларны аңлауга, һәрьяклап үсеш алган шәхес тәрбияләү эшендә ярдәм итә. Шуны әйтергә кирәк: газета һәрвакыт илнең белемле, мәдәниятле, намуслы гражданнарын тәрбияләүне үзенең төп бурычы дип саный.

Үзгәртеп кору җилләре йогынтысында газетага да яңа юнәлешләр сайларга, үзгәрергә туры килә. Иң зур үзгәреш газетаның исеменнән башлана. Исем сайлаганда, «Сабантуй»ның татар халкының иң яраткан бәйрәме булуына игътибар бирелә. Газета иҗатчылар көч сынау мәйданына әверелер дип, яңа исем белән чыга башлый [25, б. 248–249].

Газета асылына караган үзгәрешләр бик күп бәхәсләр, каршылыклар тудыра. Аларда бөек даһиның исемен сакларга чакыру, газетаның кыйбласы үзгәрүдән курку белән бәйле шикшөбһәләр туып тора. Баш мөхәррир барлык укучылар белән бергә сынауларны үтү юлында фикерен белдереп: «Әлеге хатлар исә безне сөендерде дә, көендерде дә. Беренчедән, безнең гәзитебезне укыйлар, укучыларыбыз битараф түгелләр, һәм без 70 ел буена Ильич исеме астында алып барган тәрбиябез халык күңеленә шулкадәр сеңгән ки, аларның фикерен бер көндә генә үзгәртергә тырышу дөрес тә булмас иде. Чөнки бу очракта аларның һәрберсе хаклы. Без үзебез дә ике ут арасында... – дип яза Р. Миңнуллин, бу чорны искә алып. – Шул рәвешле газета тиражы кимүгә йөз тотты. Моның объектив сәбәпләре күп: пионер оешмасы юкка чыкты, балалар тормышына телевидение, интернет, компьютерлар керде. Балаларның уеннары, кызыксынулары,

мавыгулары хәзер бөтенләй башка» [24, б. 242–244].

2014 елда газетаның форматын үзгәртү нисбәтеннән, Р. Миңнуллин үзенең чыгышында: «Кызганыч, «Сабантуй»ны газета килеш саклап кала алмадык. Без аны бетерүчеләр булганбыздыр», – диде 41 ел гомерен «Яшь ленинчы»/«Сабантуй» газетасына багышлаган әдип.

2014 елдан «Сабантуй» айлык журнал буларак үзгәртелә. Журнал аудиториясе булып яшүсмерләр кала. Журналның максаты – укучыларның мәгълүмати-күңел ачуын һәм рухи-әхлакый үсешен тәэмин итү. Балаларның иҗади үсешен, зур тормыш юлына әзерләү әһәмиятле юнәлеш булып тора. Журнал күбрәк визуаль контент, заманча дизайн, уңайлы формат һәм югары сыйфатлы кәгазьдә басылуы белән аерылып тора. «Сабантуй» журналы айга ике тапкыр чыга. Шулай ук аның интернет-сайты да шул исемдә. Ул басма материаллар белән беррәттән, мультфильмнар, уеннар, музыкаль бизәлеш белән тулыландырылган. Журналның социаль челтәрләр белән дә элемтәсе тыгыз.

## Нәтиҗә

Шул рәвешле, татар балалар матбугаты бер гасыр дәвамында илдәге сәяси, икътисади, мәдәни йогынтылар астында үзгәреп торган. Алар журнал һәм газета басмалары буларак, балалар мәнфәгатен яклаучы, аларның ихтыяҗларына җавап бирүче даими басмалар буларак нәшер ителеп торганнар.

Төрле яшьтәге балаларның кызыксынуларын, ихтыяҗын күз уңында тоткан «Ялкын» журналының чишмә башы 1924 елда Муса Җәлил оештырган «Кечкенә иптәшләр»гә барып тоташа. 1929 елдан «Октябрь баласы», 1933 елдан «Пионер каләме» булып чыгып, 1957 елдан «Ялкын» журналы буларак, балалар матбугатында бүгенге көнгә кадәр сакланып кала.

Балаларга адреслап чыгарылган «Яшь ленинчы» газетасы 1923 елдан «Яшь пионер» исеменнән башлангычын ала. 1924 елдан «Яшь ленинчы» булып чыга башлый. Газета шактый сикәлтәле юл үтә. 1936–1941 елларда мөстәкыйль басма булудан туктап тора. Бары тик «Кызыл Татарстан» белән берләштерелеп, «Пионер бите» сәхифәсе рәвешендә генә чыга. Шуннан соңгы егерме ел газета тарихында «ак тап» булып кала. Бары тик 1961 елдан гына газета элекке традицияләренә кабат әйләнеп кайта. XX гасыр ахырындагы үзгәртеп кору шартларында газетаның исеме «Сабантуй» (1991 елдан) дип үзгәртелә. 2014 елдан исә «Сабантуй» балалар журналы буларак нәшер ителә башлый.

Ике басма да йөз ел дәвамында татар халкының язмышын чагылдырып, яшь буынны үз артыннан ияртеп, тәрбия бирә. Аларда басылып чыккан һәр мәгълүмат, мәкалә, рәсем, әдәби әсәр балаларның юлдашына әверелә, кызыксыну тудыра. Бу басмаларны чыгаруга көч куйган һәр хезмәткәр, журналист, әдип, рәссам балалар дөньясын аңлап, аларның ихтыяҗына җавап бирергә омтылып эшли. Алар балаларның күңел халәтен, психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып, Туган илен, халкын яратучы шәхес тәрбияләүгә зур көч куя [27].

Дәлил итеп «Ялкын», «Яшь ленинчы» мәктәбен үткән заманча язучыларның һәм журналистларның күңелгә үтеп керерлек истәлекләрен китерәсебез килә.

**Васил Гарифуллин, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры**: «Без мәктәптә укыган чор тарихка «торгынлык чоры» дигән атама белән кереп калды. Ә шулай да тик тормадык без, бик актив тормыш белән яши идек. Мәктәптә атна саен төрледән-төрле чаралар узып тора, һәммәсендә катнашырга тырышабыз: биибез дә, җырлыйбыз да, рәсемен дә ясыйбыз, агачтан, балчыктан сыннар да иҗат итәбез. Ә инде хикәя-шигырьләр язу, бу иҗат җимешләрен классның яки мәктәпнең стена газетасында гына түгел, район газетасында, республика басмаларында күрү әйтеп бетермәслек шатлык китерә иде.



Хәтеремдә, «Ялкын» журналына беренче шигыремне икенче сыйныфта укыганда җибәрдем. Озак та көттермичә, журналдан бик

матур конвертлы хат килеп төште. Шигырьне әлегә бастыра алмаулары турында хәбәр иткәннәр, әдәби әсәрне ничегрәк язарга, теманы каян алырга, образларны ничек төзергә кирәклеген дә тәфсилләп аңлатканнар редакция хезмәткәрләре. Ләкин бу хат күңелемне бер дә төшермәде, киресенчә, бу хатны сабакташларыма күрсәтеп мактанып та йөрдем әле. Конверты бигрәк зәвыклы, матур иде шул. Авыл баласының андый әйберне бөтенләй күргәне юк. Сабакташларым да минем үрнәккә иярде, үз әсәрләрен Казанга юллый башладылар. Авылыбызга «Ялкын»нан, «Яшь ленинчы»дан хатлар килергә тотынды. Беренче булып миннән югарырак сыйныфта укучы Марсель Кадыйровның шигыре дөнья күрде. Сугыштан яраланып, бер аягын калдырып кайткан әтисенә багышланган иде ул. Марсель хәзер танылган галим һәм спорт судьясы, шигырьләр язуын дәвам итә. Ә менә мин күпме генә язсам да, шагыйрь булып китә алмадым. Язмаларым соңрак район газетасында дөнья күрә башлады һәм мин югары сыйныфларда укыганда, шагыйрь түгел, ә журналист булу хыялы белән яна идем инде.

«Ялкын»нан килгән хатларны хәзер дә еш кына алып укыйм. Ис-акылларың китәрлек бит, танылган язучылар, шагыйрьләр, публицистлар үзләренең вакытларын кызганмыйча, һәр балага аерым-аерым киңәшләрен биргәннәр, өмет канатларын кисмәскә, иҗатка, әдәбият дөньясына кертеп җибәрергә тырышканнар! «Ялкын» мәктәбен узган буынның бер вәкиле булуым белән чиксез горурланам!» [28]

**Ләбиб Лерон, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире,**

«“Яшь ленинчы” газетасы бик затлы газета иде. Ул күбебезгә канат куйды. «Яшь ленинчы»да чыккан кешеләр берсе дә югалып калмады – әдәбиятыбызда һәм мәдәниятебездә тирән эз калдырдылар» [29].

**Әдәбият**


1. Татарская периодическая печать: научно-энциклопедическое издание / Сост. и науч. ред. Р. А. Айнутдинов, З. З. Гилязев. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. 200 с.
2. *Мәрдәнов Р.* «Тәрбияи-этфаль» журналына йөз ел // Казан утлары. 2007. № 2. Б. 180–188
3. *Мәрдиева М. Б.* Татар журналистикасы тарихы буенча очерклар. Уку ярдәмлеге. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2003. 132 б.
4. *Миңнуллин Ж.* «Ялкын»ның өч абыйсы // Ялкын. 1994. № 3. Б. 6–7
5. *Ибраһимова Ф.* Сабыйларны үз итеп... (Татар балалар әдәбияты). – Казан: Иман. 1998. 224 б.
6. *Ибраһимова Ф.* Балачак юлдашы: «Балалар дөньясы» журналы чыга башлауга 70 ел // Ялкын. 1987. № 3
7. *Абызова Р. Р.* Татарские детские журналы (1907–1918) и судьбы их создателей // Вестник Волжского университета имени В. Н. Татищева, том 1. 2020. № 4. С. 59–67.
8. *Галиева А. Ф.* Сиксәндә дә ул бала // Казан утлары. 2004. №3. Б.180–182
9. *Мөслимова Ф.* «Ялкын» – дуслык учагы // Татарстан. 1999. № 5.
10. *Фаткуллина Р.* «Ялкын» и детская литература // Детская литература. 1979. № 9.
11. *Хафизова Р.* Беренче карлыгач / Р. Хафизова // Ялкын. 1971. № 2. – Б. 22–23.
12. *Хафизова Р.* Балачакка кире кайтыр идем // Ялкын. 1994. № 2. Б. 4–7.
13. *Хафизова Р.* Уртак эшебез // Совет мәктәбе. 1984. № 5.
14. *Галиахметова А. Ф.* Литературно-художественный материал в татарских детских журналах начала XX века: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 28 с.
15. *Госман Х.* Рухи кояшым // Яшь ленинчы. 1974. 9 ноябрь.
16. *Арсланов Н.* Бәйрәмегез белән котлыйм // Яшь ленинчы. 1974. 9 ноябрь.
17. *Зарипов Х.* Кутуй пионерлар белән сөйләшә // Яшь ленинчы. 1974. 14 ноябрь.
18. *Зарипов Х. Һ.* Такташ «Яшь ленинчы»да // Яшь ленинчы. 1974. 28 август. Б. 2–3.
19. *Зарипов Х.* Пионер галстуклы шагыйрь // Яшь ленинчы. 1974. 28 август. Б. 2–3.
20. *Зарипов Х.* Апуш... Алиш булды // Яшь ленинчы. 1974. 28 август.
21. *Ибраһимова С.* «Яшь ленинчы» һәм «Ялкын» бездә кунакта // Совет әдәбияты. 1983. № 9. Б.188.
22. *Якупов Х.* Юбилей котлавы // Яшь ленинчы. 1974. 10 октябрь.
23. *Айнутдинов Р.* «Сабантуй» – газета для детей и подростков // URL: https://tatarica.org/ru/razdely/sredstva-massovoj-informacii/periodicheskie-izdaniya/sabantuj (дата обращения 12.12.2023)
24. *Миннуллин Р.* Сабантую старость не грозит // Миннуллин Р. Әсәрләр 7 т. 7 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 248–249.
25. *Галиев Ш.* Тылсымлы көзге // Яшь ленинчы. 1974. 24 март.
26. *Миңнуллин Р.* Балалар дөньясын яңгыратып // Миңнуллин Р. Әсәрләр 7 т. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 105.
27. *Ибраһимова С.* «Ялкын» һәм «Яшь ленинчы» бездә кунакта // Совет әдәбияты. 1983. № 9. Б. 188.

28. *Гарифуллин В.* Ялкынланып иҗат иткән идек // «Tatarica» журналы архивы. Кульязма. 2024. 1 б.

29. Татар язучылары «Яшь ленинчы» газетасында эшләгән чорларын искә алдылар. 19.04. 2024 // URL: https://tatar-inform.tatar/news/tatar-yazucylary-yas-lenincy-gazetasynda-eslagan-corlaryn-iska-aldy-5886467 (мөрәҗәгать итү датасы: 19.04. 2024)

---

# ИЗ ИСТОРИИ ТАТАРСКОЙ ДЕТСКОЙ ПРЕССЫ

**Гульнара Фандасовна Замалетдинова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
gulnara.zamaletdinova@kpfu.ru.

**Альфия Рухулловна Мотигуллина**,
Поволжский государственный университет физической культуры, спорта и туризма,
Россия, 420010, г. Казань, деревня Универсиады, д. 35,
alfiya311065@mail.ru.

В данной статье, посвященной 100-летнему юбилею журнала «Ялкын» и газеты «Яшь ленинчы», представлены материалы по истории татарской детской печати, исследована роль этих печатных изданий в воспитании детей, укреплении их гражданской идентичности. Доказана эффективность школы юных корреспондентов, подарившей татарскому народу известных писателей, журналистов, художников, композиторов и других деятелей культуры.

**Ключевые слова:** татарская детская пресса, журналы «Ялкын», «Сабантуй», «Салават күпере», газета «Яшь ленинчы»